Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының

Чуаш-Кичүе авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

2015 елның 27 гыйнвар 1 №

**Чуаш-Кичүе авыл җирлеге башлыгының «2014 елда Чуаш-Кичүе авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2015 елга бурычлар турында» хисабы.**

Чуаш-Кичүе авыл җирлеге башлыгы Н.Р.Закирова «Чуаш-Кичүе авыл җирлеге башлыгы хисабы 2014 ел йомгаклары буенча башкарылган эшләр турында»докладын тыңлап фикер алышканнан соң

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чуаш-Кичүе авыл җирлеге Советы КАРАР ИТӘ:

1.Чуаш-Кичүе авыл җирлеге башлыгының «2014 елда Чуаш-Кичүе авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2015 елга бурычлары турында» хисабын игътибарга алырга.
2. 2014 ел йомгаклары буенча Чуаш-Кичүе авыл җирлеге башлыгы эшен канәгатьләнерлек дип санарга.
3. Халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрүне алга таба да мөһим бурыч дип санарга, моның максатларында нәтиҗәле чаралар күрергә:

- халыкны эш белән тәэмин итү һәм җирлекләрнең икътисадын ныгыту максатларында, район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе белән берлектә, 2011-2015 елларга кабул ителгән авыл җирлекләре территорияләрен социаль-икътисадый үстерү программасын эзлекле рәвештә үтәүне дәвам итәргә;

- стабильләштерү финанс хәле өчен җылылык һәм энергетика ресурсларын экономияле файдаланырга, чыгымнарны оптимальләштерү буенча максатчан эшне дәвам итәргә һәм салымнарны тулысынча җыюга ирешергә.

-шәхси ярдәмче хуҗалыкларда авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү өчен шартлар тудыру, авыл халкына җитештерелгән продукцияне сатарга ярдәм итү, хуҗалыкларда терлекләрнең баш санын арттыруга ирешү, гаилә фермалары төзүдә шәхси хуҗалыкларга һәрьяклап ярдәм күрсәтү.

- авылда кече эшкуарлык шартлары тудырырга һәм халыкны эшкуарлыкны үстерү буенча Россия һәм республика программаларында актив катнашуга җәлеп итү буенча агитация-аңлату эшләре алып барырга.

- урыннарда әхлакый, физик тәрбияне яхшырту, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, халыкның ялын оештыру буенча максатчан эш алып барырга,

- халыкка нәтиҗәле һәм сыйфатлы медицина ярдәменнән файдалануны арттыру, балалар авырулары профилактикасын үткәрү чараларын күрергә;

- авылда ял итүне, массакүләм спорт һәм физкультура-савыктыру эшен оештыру өчен шартлар тудырып, мәдәниятне, балалар һәм яшьләр мәгарифен алга таба үстерүне тәэмин итәргә;

- хәйрия эшчәнлегенә ярдәм итү һәм аны үстерү буенча гамәлгә ашыруны дәвам итәргә

- хокук бозуларны профилактикалау буенча халыкны, иҗтимагый оешмаларны җәлеп итеп, профилактик эшнең нәтиҗәле формаларын эшләргә.

4. Авыл җирлеге башлыгы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белән берлектә максатта халыкны эш белән тәэмин итү дәрәҗәсен күтәрү, эш бирүчеләрнең ЦЗН белән иҗтимагый эшләрне оештыру буенча уртак эшчәнлек турында килешүләрен төзү эшен оештырырга.

5. Чуаш Кичүе авыл җирлеге башкарма комитеты авыл җирлеге бюджетына салым түләүләренең вакытында керүен тәэмин итү буенча чаралар күрү.

6. Чуаш Кичүе авыл җирлеге башкарма комитеты авыл җирлеге башлыгы докладында әйтелгән кисәтүләрне һәм тәкъдимнәрне гомумиләштерергә, аларны тормышка ашыру буенча чаралар планын эшләргә.

Чуаш-Кичүе авыл җирлеге Советы Рәисе: Н.Р.Закирова